**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2406**
**22.05.2020**

Башкарма комитетның 2013 елның 2 октябрендәге 5950 номерлы карары белән расланган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 2 октябрендәге 5950 номерлы карары (2016 елның 27 июнендәге 3269 номерлы, 2017 елның 30 гыйнварындагы 394 номерлы, 2017 елның 29 сентябрендәге 5872 номерлы, 2018 елның 28 апрелендәге 2398 номерлы, 2018 елның 9 ноябрендәге 6593 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.5 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) яшәү урыны буенча торак урында теркәлгән гражданнарның санын раслаучы мәгълүматлар»;

2) 2.6 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:

- аерым затның (булган) күчемсез милек объектларына хокуклары турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;

- күчемсез милек объектына хокуклар күчү турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;

- күчемсез милек объектының төп характеристикалары һәм аңа теркәлгән хокуклар турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;

- үлүне дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүматлар;

- яшәү урыны буенча торак урында теркәлгән гражданнар санын раслаучы мәгълүматлар;

- торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану турында карар (граждан яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урында яшәгән очракта);».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет<br>
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов